**А.Алиш – балалар язучысы**
**(“Сертотмас үрдәк” әкияте буенча)**
темасы буенча сингапур технологиясен кулланып күрсәтелгән
әдәбият дәресенең план-коспекты .
5 сыйныф,рус төркеме.

Әгерҗе шәһәренең Таҗи Гыйззәт
исемендәге 3 нче гомуми урта
белем бирү мәктәбенең
татар теле һәм
әдәбияты укытучысы
Хәсәнова Фәридә Искәндәр кызы

Әгерҗе шәһәре,2014 ел.

**Тема:** А. Алиш ."Сертотмас үрдәк" әкияте.

**Максат:** 1. А. Алишның тормыш юлы һәм иҗаты белән ныграк таныштыру.

2. "Сертотмас үрдәк" әкиятен укып, анда катнашкан образлар турында мәглүмат бирү,тыңлап аңлау, аңлап сөйләү күнекмәләрен камилләштерү,актив аралашуга тарту,төркемнәрдә эшләү күнекмәләрен үстерү,бердәм хәрәкәт итәргә, белем алырга өрәтү,өйрәнгән сүзләрне монологик сөйләмгә кертү, әкиятнең тәрбияви якларын күрсәтү.

3. Китап укуга омтылыш тәрбияләү; ышанычны аклау, сер саклау, җаваплылык тою кебек хис-тойгылар тәрбияләүне дәвам иттерү.

**Җиһазлау**: "Сертотмас үрдәк" әкияте буенча рәсемнәр, ноутбук, интерактив такта,төрле биремнәр язылган карточкалар, ручка

**Дәрес тибы**: белемнәрне ныгыту.

**Төре:** әңгәмә.

Укучылар төркемнәрдә эшлиләр .Традицион булмаган утыру(йөзгә-йөз,җилкәгә-җилкә куеп.)

**Дәрес оештыру.**

**I. Оештыру.**

1. Исәнләшү(укытучы һәм бер-берсе б-н исәнләшәләр.)
2. Уңай психологик халәт булдыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Сорауларга интерактив тактада җавап бирү.
   - Укучылар. Без сезнең б-н А.Алиш турында беләбез инде. Аны күпме дәрәҗәдә беләбез,тикшерик.

     Тест эшләү *(тест сораулары экранда күрсәтелә)*.Төркемнәрдә эшлиләр. ***Раунд Тейбл(по кругу) 1 минут*** вакыт бирелә,җавапларны язарга һәрбер өстәлгә таблица таратыла.Ахырдан тикшерәләр . Һәр төркемнән 2 нче номерлы укучылар җавап бирә. Бер-берсен мактыйлар.

1. А. Алиш кайчан туган?
а) 1944 ел, 15 сентябрь
б) 1908 ел, 15 сентябрь
в) 1943 ел, 25 август
2. А.Алиш нинди гаиләдә туа?
а) крестьян гаиләсендә
б) мулла гаиләсендә
в) укытучы гаиләсендә
3. А.Алишны балаларның

5. А.Алиш эшләгән "Пионер каләме" журналы хәзер ничек дип атала?
а) "Салават күпере"
б) "Сабыйга"
в) "Ялкын"
6. А.Алишның дусты
а) М.Җәлил
б) Ф.Яруллин

яраткан язучысы иткән жанр
а) шигырь
б) әкият
4. Авторның беренче әкияте
а) “Капкорсак патша”
б) “Чукмар белән Тукмар”

в) Ә. Фәйзи
7. Быел А.Алишның тууына ничә ел?
а) 90
б) 106
в) 110

| | **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **6** | **7** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **а** | | | | | | | |
| **б** | | | | | | | |
| **в** | | | | | | | |

Экранга җаваплар чыгарыла.

## III. Осталык һәм күнекмәләрне формалаштыру.

1. Дәреснең темасын әйтү, максаты белән таныштыру.
2. Яңа сүзләр өстендә эшләү (интерактив тактада) – *6 слайд*.

Карточкага язылган сүзләрне парларда чиратлашып кабатлау***.(Релли-Робин- 30 секунд***.). Тактадан тәрҗемәләрен тикшерү.Аннан соң Таймд Раунд Робинны кулланып ,1 минутта сүзтезмәләр ,сүзтезмәләрдән җөмләләр төзеп, бер-берсенә җөмләләрне әйтү, 1 минуттан соң һәр өстәлдән 3 нче номерлы укучы җөмләләрне басып әйтә.

3. Әкиятнең эчтәлеген (өй эше) интерактив тактадагы рәсемнәр буенча терәк сүзләр ярдәмендә сөйләү***. Релли Тейбл-*** бирелгән сүзтезмәләр б-н җөмләләр төзеп икесенә бер биткә язу.(янәшә утырган парлары б-н эшлиләр)Ахырдан тикшерәләр:һәр пар басып,җөмләләрне чиратлап укыйлар. Бер-берсен мактыйлар.

- Әкияттә сүз нәрсә турында бара?

*7 слайд*. Терәк сүзләр. *(борын заманда, яңа хәбәрләр, сер итеп, беркөнне, беркемгә, хуҗаны эзләргә)*

8. Интерактив тактада эш. Мәкальләрне дәвам итү – *8 слайд*

Сер тотмас – дус тапмас.

Күп сөйләгән авыз - бәхетсезлек капкасы.

***Микс Пэа Шэа*** алымын кулланам.Укучылар басалар,музыка куям ,бииләр.Музыка туктагач,үзләренә пар табалар. – Мәкальне укыйм,һәр парда да бер укучы икенчесенә мәкальнең мәгнәсен аңлата. Аннары һәр пардан берәр укучы мәкальнең мәгнәсен сыйныфка ишетелерлек итеп әйтә.Шулай ук икенче мәкальне дә эшлиләр.

9.- Мәкальләрнең кайсы үрдәк образына туры килә?

- Үрдәккә нинди сыйфат җитеп бетми? *(җаваплылык)*

-Бу мәкалләр нинди кешеләр турында?(күп сөләшүче,сер тотмаучы)

-Дөрес. Әлеге мәкалләр безнең әкиятебезгә туры киләме?

10.Сез уңай һәм тискәре сыйфатларны күрәсез? – *9 слайд*

Уңай, тискәре сыйфатлар

| | |
|---|---|
| 1. Ышанычлы<br>2. Саран<br>3. Тырыш<br>4. Әләкче<br>5. Куркак | 6. Сабыр<br>7. Ярдәмчел<br>8. Мактанчык<br>9. Кешелекле<br>10. Алдакчы |

9. - Нинди кеше хөрмәтле, дәрәҗәле була?(ышанычлы,кешелекле,сабыр)

- Үрдәкнең дәрәҗәсе бармы?

**IV. Йомгаклау.**

1. Дәресне йомгаклап, нәтиҗә ясау.

***Эй Ар Гайт***.Әйтелгән фикерләр дөрес басалар,дөрес булмаса утыралар.

- бүгенге дәрестә без ялганчы үрдәк турында сөйләштек.
- без “Сертотмас үрдәк” әкиятен өйрәндек.
- әкиятне укыгач,ышанычлы булырга кирәк дигән фикергә килдек.
- дәрес сезгә ошадымы?

2. Актив укучыларны билгеләп, билгеләр кую.

**10. Өйгә эш бирү.** *Слайд 10.*

Ошаган өзеккә рәсем ясап сөйләргә.